**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

# Об утверждении перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей

В соответствии со статьей $20^{1}$ Федерального закона «О государственной гражданской службе Российской Федерации» и статьей $17^{1}$ Закона Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемый перечень должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей.

2. Рекомендовать органам местного самоуправления в Республике Татарстан учитывать положения настоящего Указа при разработке и утверждении перечней должностей муниципальной службы, при замещении которых муниципальные служащие обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
22 апреля 2013 года
№ УП-329

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан
от «22» апреля 2013 года
№ УП-329

**Перечень**
**должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей**

1. Должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, включенные в пункт 1 перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при назначении на которые граждане и при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, утвержденного Указом Президента Республики Татарстан от 30 декабря 2009 года № УП-701 «Об утверждении перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при назначении на которые граждане и при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей» (далее – Перечень должностей).

2. Должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, включенные в перечни должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан в государственных органах Республики Татарстан, при назначении на которые граждане и при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, утвержденные руководителями государственных органов Республики Татарстан в соответствии с пунктом 2 Перечня должностей.

___________

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның $20^{1}$ статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының $17^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген эшләгәндә һәм раслаганда әлеге Указ нигезләмәләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-329

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның «22» апрелендәге
ПУ-329номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы белән расланган исемлекнең 1 пунктына кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә бурычлы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары (алга таба – Вазыйфалар исемлеге).

2. Исемлекнең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре тарафыннан расланган, Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфага билгеләнгәндә һәм аларны биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары.

___________